КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 февраль г.Казань № 140

Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы куллачучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 март, 229 нчы карары белән расланды

Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына кечкенә сөт парклары территориясендә сөтчелек юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тотуга бәйле чыгымнар өлешен каплауга (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

Субсидия Татарстан Республикасы авыл территориясендә яисә авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек алып баручы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булып торучы «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 193-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативлары рәвешендә төзелгән авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативларына (авыл хуҗалыгы кулланучылары кредит кооперативларыннан тыш) бирелә (алга таба - сайлап алуда катнашучылар).

1.2. Бу Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

авыл агломерацияләре - авыл территорияләре, шулай ук шәһәр тибындагы поселоклар һәм кече шәһәрләр, аларның территорияләрендә даими яшәүче 30 мең кешедән артмаган. Авыл агломерацияләре исемлеге Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеген һәм Татарстан Республикасының авыл агломерацияләре исемлеген раслау турында» 2020 елның 05 мартындагы 48/2-б номерлы боерыгы белән расланды;

авыл территорияләре - муниципаль район чикләрендәге гомуми территория белән берләштерелгән авыл җирлекләре яисә авыл җирлекләре һәм авылара

территорияләр, шәһәр җирлекләре, муниципаль округлар, шәһәр округлары составына керә торган авыл торак пунктлары (территорияләрендә Татарстан Республикасының административ үзәкләре булган шәһәр округларыннан тыш). Авыл территорияләре исемлеге Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеген һәм Татарстан Республикасының авыл агломерацияләре исемлеген раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 48/2-б номерлы боерыгы белән расланды;

ферма - мөгезле эре терлекләрне тоту, ашату һәм аларны тәрбияләү өчен билгеләнгән аерым терлекчелек бинасы рәвешендәге төзелеп беткән объект, проект куәте - 16-23 башка яисә 24 башка кадәр яисә аннан да күбрәк, кечкенә сөт паркы территориясендә урнашка;

мөгезле эре терлек - сөтчелек юнәлешендәге таналар һәм сыерлар;

кечкенә сөт паркы - авыл территориясендә яисә авыл агломерациясендә урнашкан, кимендә 0,8 гектар мәйданлы, ул милек хокукында сайлауда катнашучыныкы йә кимендә 7 ел дәвамында озак сроклы арендада булган, кимендә дүрт ферма урнаштырылырга мөмкин булган җир кишәрлеге.

1.3. Субсидия бирү шартлары түбәндәгеләр була:

субсидия алган көннән алып 12 ай эчендә ферманы мөгезле эре терлекләрнең баш санын проектлау куәтенә кадәр комплектлау (субсидия алучының банк счетына акчалар кергән көн субсидия алган көн булып тора) һәм ферманы проектлау куәтенә кадәр җиһазландырган көннән соң 5 ел эчендә мөгезле эре терлекләрнең баш санын саклап калу йөкләмәсе;

«Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре булган физик затларга - сайлап алуда катнашучы әгъзаларына - фермаларны сатып алу мөмкинлеге белән арендага тапшыру йөкләмәсе.

1.4. Субсидия бирү әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә тиешле финанс елына бюджет акчаларының баш бүлүчесенә - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.5. Субсидия Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

1.6. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре - 2020 елдан да иртәрәк кылынмаган КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актка кертелгән фермалар төзүгә бәйле төзелеш һәм монтаж эшләренә чыгымнар.

1.7. Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

1.8. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы кимендә биш граждан һәм (яисә) 10 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре берләшмәсе (ассоциацияләнгән әгъзалардан тыш);

сөт сатып алу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен матди-техник һәм кадрлар ресурслары булу.

## II. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

2.2. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм Министрлыкның муниципаль районнарда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба - Идарәнең) исемнәре, урнашу урыннары, почта адресы һәм электрон почтасы адресы;

бу Тәртипнең 3.7 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 2.5, 2.6 һәм 3.2 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – Килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасы, ул сайлауда җиңүчене билгеләгән көннең иртәгесеннән соңгы 14 календарь көннән дә соңга калмаска тиеш.

2.2. 7. Сайлап алуда катнашучылар гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормаса,

бу Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмасалар.

2.3. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча Идарәгә заявка бирә, анда катнашучының сайлап алуга бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында әлеге Тәртипнең 1.8 пунктында күрсәтелгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы биргән заявка һәм сайлап алга бәйле башка мәгълүмат турында мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучының ризалыгы түбәндәге документларны кушымта белән бирелә:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча фермалар арендаторларыннан сөт сатып алу буенча бизнес-план;

сөт сатып алу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен сайлап алуда катнашучының матди-техник ресурслары булуын раслый торган белешмә;

башкарылган эшләрне КС-2 формасы буенча кабул итү актлары һәм фермалар төзүгә факттагы чыгымнарны раслый торган фермалар төзү буенча КС-3 номерлы

форма буенча башкарылган эшләр  һәм чыгымнар хакы турында белешмәләр;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга һәм (яисә) төзелеш материалларын сату-алу шартнамәләрен башкаруга подряд шартнамәләренең күчермәләре;

2020 елдан да иртәрәк булмаган чорда башкарылган эшләр өчен түләүне раслаучы түләү йөкләмәләре күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының милкендә ферма  булуын раслый торган документларның күчермәләре;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында документлар күчермәләре;

агымдагы финанс елның хисап кварталында 1-СПР номерлы  форма буенча сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап күчермәләре;

фермаларны сатып алу мөмкинлеге белән сайлап алуда катнашучы әгъзалары тарафыннан фермаларны арендалау шартнамәләренең күчермәләре;

гариза биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән күчемсез милек объектына төп сыйфатламалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

субсидия алган көннән алып 12 ай эчендә мөгезле эре терлекләрнең баш санын ферманың проект куәтенә кадәр фермаларны комплектау буенча һәм субсидияләр бирү елынан соң килүче елның 1 гыйнварыннан башлап 5 ел дәвамында мөгезле эре терлекләрнең баш санын саклап калу йөкләмәсен;

үз инициативасы буенча юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрын теркәү кәгазе күчермәсе һәм салым органын белешмәсе, ул сайлауда катнашучының  салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар  түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юклыгын раслый (КНД буенча Код 1120101 формасы). Әгәр күрсәтелгән документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган булса, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр битенә номерлар сугылган, сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән имзаланган һәм сайлап алуда катнашучы мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Документларда чистарту һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән имзаланган һәм сайлап алуда катнашучы мөһере белән (булган очракта) таныкланган төзәтмәләрдән  тыш.

Идарәгә заявкалар кабул итү срогы башланганчы яисә заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң (шул исәптән почта элемтәсен оештыру аша) кергән заявкалар теркәлми, шул исәптән алга таба сайлап алулар уздырганда да да, каралмый һәм Идарә күрсәтелгән заявкалар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә аларны почта элемтәсе хезмәте аша сайлауда катнашучыларга теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп кире кайтара.

Теркәлгән заявкалар үзләренә беркетелгән документлар белән сайлап алуда катнашучыларга кире кайтмый һәм Идарәдә саклана.

2.4. Заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганга кадәр сайлап алуда катнашучы ирекле рәвештә язылган гариза буенча заявканы (шул исәптән заявкага үзгәрешләр

кертү һәм яңа заявка бирү максаты белән) кире алырга хокуклы.

Әгәр дә заявкалар бирү срогы чыкканга кадәр заявкага үзгәреш кертү сайлап алуда катнашучы тарафыннан яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә Идарә тарафыннан алынса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турындагы хәбәрнамә гамәлдә дип санала, шул ук вакытта заявка кергән көнне чиратлылык нигезендә теркәлә.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар Идарәдә кәгазь чыганакта тапшырыла.

Сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә билгеләнгән сайлап алуны уздыру срогы дәвамында Идарә заявкаларны «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасына керү тәртибендә терки.

Идарәгә сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган барлык документларның исемнәре, аларда язылган кәгазьләр саны Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә төзелә. Тапшырылган документлар терәлгән исемлек белән чагыштырылганнна соң Идарәнең җаваплы хезмәткәренә тапшырыла. Документлар кабул иткәндә, документлар кабул итү датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, исемлек битендә документлар кабул итүне раслый торган тамга ясала. Тапшыру кәгазенең бер нөсхәсе сайлап алуда катнашучыда кала, ә икенчесе документлар пакетына теркәлә.

Заявка һәм документлар кабул ителгәндә аларның тулылыгын һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү башкарылмый.

Сайлап алуда катнашучы бер генә заявканы сайлап алуга тәкъдим итәргә хокуклы.

2.6. Заявкаларны карау максатларында Идарә җаваплы затларны Идарә хезмәткәрләре арасыннан гаризаларны карау буенча билгели (алга таба - Идарә хезмәткәрләре).

Заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң өч эш көне эчендә Идарә хезмәткәрләре:

заявкалар әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү датасыннан һәм вакытыннан чыгып, аларга кушымта итеп бирелгән документлар белән заявкаларны әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән заявкаларны кире кагу өчен нигезләрнең булу-булмавына, аларны карау стадиясендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән заявкаларны кире кагу өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерәләр, сайлап алу таләпләренә һәм критерийларына туры килүне тикшерәләр;

заявкаларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында һәм катнашучының заявкаларны сайлап алу критерийларына яисә кире кагу критерийларына туры килүе турында карар кабул итә, ул Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча заявкаларны карау турында беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Идарә башлыгы тарафыннан раслана (алга таба - беркетмә);

әлеге Тәртипнең 2.7 пункты нигезендә субсидия күләмен исәпләп чыгаралар һәм Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча тиешле субсидия турында белешмә-исәп-хисап төзиләр (алга таба - белешмә-хисап).

Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, аларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризалар туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтеп;

сайлап алуда катнашучы исеме һәм әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә субсидия күләменең исәп-хисабы.

2.7. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum_{i=1}^{n} (Z_i \times 0{,}7) + \sum_{k=1}^{r} (Z_k \times 0{,}7),$$

монда:

i - 16дан 23 башка кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары;

n - 16дан 23 башка кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары саны;

$Z_i$ - 2020 елдан да иртәрәк булмаган башкарылган эшләрне КС-2 номерлы форма буенча кабул итү турындагы актларга кертелгән 16дан 23 башка кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары төзүгә бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүнең фактагы чыгымнары (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш), сум;

k - 24 һәм аннан да күбрәк баш мөгезле эре терлек асрау фермалары;

r - 24 һәм аннан да күбрәк баш мөгезле эре терлек асрау фермалары саны;

$Z_k$ – 2020 елдан да иртәрәк булмаган башкарылган эшләрне КС-2 номерлы форма буенча кабул итү турындагы актларга кертелгән 24 баш һәм күбрәк кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары төзүгә бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүнең фактагы чыгымнары (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш), сум;

Бер фермага исәпләгәндә субсидиянең иң чик күләме түбәндәгеләр тәшкил итә:

16дан 23 башка кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары өчен– 2,0 млн. сум;

24 баш һәм аннан да күбрәк мөгезле эре терлек асрау фермалары өчен - 3,0 млн. сум.

## III. Субсидия бирү тәртибе

3.1. Идарәләр тарафыннан тапшырылган беркетмәләр һәм белешмәләр-исәп-хисаплар нигезендә Министрлык заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килүче көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында карар кабул итә һәм бердәм порталда һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алу нәтиҗәләре турында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматны урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

3.2. Заявкаларны карау стадиясендә кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 1.8 һәм 2.2 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан гаризалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң гаризалар бирелү;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

3.3. Субсидия Министрлык белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма һәм белешмә-исәп нигезендә төзелә торган Килешү нигезендә субсидия алучыга бирелә.

Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән өч эш көне эчендә субсидия алучылар белән кәгазь саклагычтагы ике нөсхәдә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

субсидияне кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидияләр алучы, субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат тарафыннан килешүгә имза салуны тәэмин итмәгән очракта, килешү төзүдән читләшкән дип танылa.

Министрлык язма рәвештә субсидия алучыга Килешү төзелүдән читләшкән дип танылганнан соң биш эш көне эчендә аңа субсидия бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында хәбәр итә.

3.4. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның бу Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның

тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

3.5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счеттан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Идарәләрнең шәхси счетларына субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Министрлык акча күчерә.

3.6. Идарә тарафыннан субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә, башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерә.

3.7. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - ферманың тиешле куәтенә туры килә торган күләмдә сөт арендаторыннан сөт сатып алу һәм сөтчелек юнәлешендәге бер сыерга исәп-хисапта кимендә биш тонна, ферманы проектлау куәтенә әзерләгәннән алып, ел саен биш ел дәвамында сөт юнәлешендәге бер сыерга исәпләгәндә.

3.8. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне бәяләү Идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV. Хисаплылыкка карата таләпләр

4.1. Субсидия алучы Идарәгә ел саен субсидияләр бирү елыннан алып 1 февральгә кадәр алты ел дәвамында түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисап;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү шартларын үтәү турында хисап.

## V. Контрольдә тотуны башкаруга карата таләпләр

5.1. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.2. Тәкъдим ителгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә хисаплана торган 60 көнлек чорда Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә - субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган очракларда, субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан, субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап бирмәгәндә ачыкланган очракларда;

әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәнең мәгънәсенә ирешелмәгән, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсеннән пропорциональ рәвештә читкә тайпылуга билгеләнә торган күләмдә.

5.3. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән

субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән соң 60 эш көне эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

5.4. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.5. Субсидияләрне файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

______________________________